ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 83 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 864824-8 номерлы федераль закон проекты турында (орфан авыруларны дәвалауны финанслауның резерв механизмын булдыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 83 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 864824-8 номерлы федераль закон проектын (орфан авыруларны дәвалауны финанслауның резерв механизмын булдыру өлешендә) хупламаска, чөнки закон проектында карала торган финанслау механизмы орфан авырулары белән интегүче затларны дарулар белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясенең барлык субъектларының тигез хокуклылыгын тәэмин итми.

2. Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда әлеге карарда бәян ителгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының карашын исәпкә алу тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 18 апреле
№ 281-VII ДС